| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | г. Казань | **БОЕРЫК** |
| №817-п | | 08.10.2015 |

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 9 декабрендәге 721-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүгә карата административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларын 2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контроль башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” 784 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 августындагы “Региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкару тәртибен раслау турында” 603 номерлы карары белән яраштыру максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 9 декабрендәге 721-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүгә карата административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүгә карата административ регламентның 1.1 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Региональ дәүләт экология күзәтчелеге дигәндә ТР ЭТРМ тарафыннан үз вәкаләтләре кысаларында юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата түбәндәге функцияләрне башкару аңлашыла:

а) атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге;

б) калдыклар (радиоактив калдыклардан тыш) белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге;

в) федераль дәүләт күзәтчелегенә тиешле су объектларыннан кала, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге;

г) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, рациональ куллануга һәм саклауга карата дәүләт күзәтчелеге;

1.2 пунктындагы өченче абзацта “ТР ЭТРМ министры (алга таба – министр), ТР ЭТРМ министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары)” сүзләрен “Татарстан Республикасының экология һәм табигый ресурслар министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасының экология һәм табигый ресурслар министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары)” сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3 Региональ дәүләт экология күзәтчелеге (алга таба – дәүләт күзәтчелеге) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

– Россия Федерациясе Конституциясе (“Российская газета” № 237, 25.12.1993) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексы, 30.12.2001, № 195-ФЗ (алга таба – РФ КоАП) (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 07.01.2002, № 1 (1 ө.), ст. 1) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Россия Федерациясе Җир кодексы, 25.10.2001, № 136-ФЗ (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 29.10.2001, № 44, ст. 4147) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Россия Федерациясе Су кодексы, 03.06.2006, № 74-ФЗ (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 05.06.2006, № 23, ст. 2381) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Махсус саклanучы табигый территорияләр турында” 14.03.1995 ел, № 33-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 20.03.1995, № 12, ст. 1024) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Хайваннар дөньясы турында” 24.04.1995, № 95-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 24.04.1995, № 17, ст. 1462) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Җитештерү һәм куллану калдыклары турында” 24.06.1998, № 89-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, № 26, 29.06.1998, ст. 3009) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Атмосфера һавасын саклау турында” 04.05.1999, № 96-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 03.05.1999, № 18, ст. 2222) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 10.01.2002, № 7-ФЗ Федераль

закон (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 14.01.2002, № 2, ст. 133) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 02.05.2006, № 59-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 08.05.2006, № 19, ст. 2060) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26.12.2008 ел, № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 29.12.2008, № 52 (1 ө.), ст. 6249) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Җир асты байлыклары турында” 21.02.1992, № 2395-1 Россия Федерациясе Законы (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 06.03.1995, № 10, ст. 823) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 12.05.2005, № 293 Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары белән расланган Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, рациональ куллану һәм саклау буенча дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 16.05.2005, № 20, ст. 1885) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Федераль дәүләт экология күзәтчелеге турында” 08.05.2014, № 426 РФ Хөкүмәте Карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 19.05.2014, № 20, ст. 2535);

– Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26.12.2008, № 294-ФЗ Федераль законны тормышка ашыру турында” 27.03.2009, № 93 боерыгы (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Россия Икътисади үсеш министрлыгының “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль законы нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында” 30.04.2009, № 141 боерыгы (алга таба – Россия Икътисади үсеш министрлыгының 30.04.2009, № 141 боерыгы) (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2009 елның 13 маенда теркәлгән, теркәлү номеры – 13915, “Российская газета”, № 85, 14.05.2009) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Россия Табигать министрлыгының “Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык һәм башка эшчәнлек башкарганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм федераль дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле объектлар исемлеген раслау турында” 08.09.2011, № 727 боерыгы (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– “Җир асты байлыклары турында” 25.12.1992, № 1722-XII Татарстан Республикасы Законы (“Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы”, № 2, 2000, ст. 43) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан

Республикасында начар метеорология шартлары чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр ташлануны җайга салу буенча эшләрне оештыру турында” 22.05.2012, № 407 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 01.06.2012, № 41; 1325 ст.) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” 21.09.2011, № 784 карарына үзгәрешләр кертү хакында” 19.03.2015, № 167 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 26.10.2011, № 40, ст. 2038) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 21.08.2014, № 603 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 26.08.2014, № 64, ст. 1987) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 06.07.2005, № 325 Карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмә (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 27.07.2005, № 28, ст. 0654) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

– Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 26.12.2003, № 1362 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү һәм министрлык компетенциясе кысаларында административ хокук бозу эшләре буенча эш башкарылышын тәэмин итү чараларын куллану вәкаләте бирелгән вазифаи затлары (дәүләт инспекторлары) исемлеге (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, № 4, 28.01.2004, ст. 0141) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).”;

1.2 пунктындагы “Дәүләт инспекцияләре” сүзләрен “Дәүләт инспекциясе” сүзләре белән алмаштырырга;

1.4 пунктындагы “1.1 пунктлары белән” сүзләрен “1.1 пункты белән” алмаштырырга;

1.6.1 пунктының 2 пунктчасындагы “юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр” сүзләреннән соң “һәм гражданнар” сүзләрен өстәргә;

1.6.2 пунктының 3, 4 пунктчаларындагы “министр боерыгы яисә министр урынбасары әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

1.6.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8, 9 пунктчалары белән тулыландырырга:

“8) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләр үтәлешен тикшерергә;

9) мәҗбүри таләпләрнең һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр үтәлешен тикшерергә.”;

1.7.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

“5) Россия Федерациясе карамагындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле Вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле Вәкилне тикшерүдә катнашырга җәлеп итәргә.”;

1.8 пунктындагы җиденче абзацта “бозуларга бәйле булган материаллар” сүзләрен “, бозуларга бәйле материаллар” сүзләренә алмаштырырга;

2.1.1 пунктындагы “Интернет” челтәрендә” сүзләрен “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә” сүзләре белән алмаштырырга;

2.3.1 пунктындагы өченче абзацны “кече предприятиеләргә карата” сүзләреннән соң “илле сәгатьтән артык булмаган” сүзләре белән тулыландырырга;

2.4.2 пунктындагы 3 пунктчаны “министр” сүзеннән соң “(министр урынбасары)” сүзләре белән тулыландырырга.

2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” 21.09.2011, № 784 карары белән расланган;

2.5 пунктындагы “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеге” дигән 2.2 таблицаны төшереп калдырырга;

3 бүлекнең икенче абзацындагы “ТР ЭТРМ 09.12.2013, № 723-п боерыгы белән расланган” сүзләрен “ТР ЭТРМ 08.12.2014, № 886-п боерыгы белән расланган” сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлектәге “ТР ЭТРМ 09.12.2013, № 723-п боерыгы белән расланган” сүзләрен “ТР ЭТРМ 08.12.2014, № 886-п боерыгы белән расланган” сүзләренә алмаштырырга;

5.1.3 пунктының өченче абзацындагы “әмернамә проекты” сүзләрен “боерык (әмернамә) проекты” сүзләре белән алмаштырырга;

5.3.5 пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

5.4.4 пунктындагы өченче абзацта “электрон сан имзасы белән” сүзләрен “көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән” сүзләренә алмаштырырга;

5.4.6 пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

7.4 пунктындагы:

беренче абзацта “Шикаятькә җавап бирелми” сүзләреннән соң “яисә шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирелми” сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “әгәр дә язмача шикаятьнең тексты аңлаешлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазифаи затка аларның компетенциясе кысаларында карап тикшерү өчен җибәрелергә тиеш, бу хакта шикаятьне теркәгән көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр дә аның фамилиясе һәм почта адресы аңлаешлы булса”;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “әгәр дә шикаятьтә, элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә, аның асылы буенча берничә тапкыр язмача җавап бирелгән сорау булса һәм бер үк вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә, дәүләт органы яки җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазифаи зат яисә моңа вәкаләт бирелгән зат, аталган шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки бер үк вазифаи затка җибәрелгән очракта, чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуларны бетерү турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә”;

7.6 пунктын “тиешле гарызнамә язмача” сүзләреннән соң “яки электрон” сүзләре белән тулыландырырга;

4 кушымтада документ аталышындагы “ӘМЕРНАМӘ (БОЕРЫК)” сүзләрен “БОЕРЫК (ӘМЕРНАМӘ)” сүзләре белән алмаштырырга;

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Х. Низамовка йөкләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев

| | |
|---|---|
| Министр урынбасары | Р.Х. Низамов |
| Хокукый тәэминат<br>бүлеге башлыгы | В.А. Тронин |